
Бүгенге санда:



Үзара салым авылны саклый. 2 бит


# Дуслык

Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе **1** апрель 2015 ел

№ 23 (10552)


**2 апрельгә һава торышы:** болытлы һава, үзгәрүчән юнәлешле җил 5-6 м/с; температура көндез +4°С, төнлә -1°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

## ЭШМӘКӘРЛЕК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ КАРАЛДЫ

Кичә районның кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән очрашу узды. Башта катнашучыларны район башлыгы Равил Кузюров сәламләде. Аннан ТР Икътисад министрлыгының эшмәкәрләргә ярдәм итү Департаменты начальнигы урынбасары Елена Шулина дәүләт ярдәмнәре турында сөйләде. Шунда ук ТР Президенты каршындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча уполномоченный эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире урынбасары Артем Шәрәфетдинов уполномоченный эшчәнлеге турында мәгълүмат китерде. Болар хакында тулырак киләсе санда укый аласыз.

## ЯТИМНӘР ФАТИРЛАР АЛА

Район башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге мәгълүматларыннан күренгәнчә, быел 16 ятим бала торак белән тәэмин ителәчәк. Шуларның 14е фатирларны Нурлаттан алырга теләк белдергән. Әлеге категория балаларга торак Яшел Үзән һәм Казанда да биреләчәк.

## ӘБУНӘ БӘЯЛӘРЕ АРТКАН

1 апрельдән 2015 елның икенче яртыеллыгына газета-журналларга язылу кампаниясе старт ала. Быел әбунәчеләрне шатландырырлык яңалык юк: районара почта элемтәсе бүлегендә әйтүләренчә, республика һәм район газеталарына бәяләр якынча 90-100 сумга артыграк куелган. Үзәк басмаларга язылу бәясе дә үскән.

# Барыбыз бергә – өмәгә!



Сирень Сәмәрханова фотосы

НУАД ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ИКЕАЙЛЫККА БЕРЕНЧЕЛӘРДӘН БУЛЫП КУШЫЛДЫЛАР

**Бүген районның торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык башланды. Нурлатлылар бу чорда "Татарстанның чиста урманнары" табигатьне саклау акциясенә дә кушылачаклар.**

Икеайлык барышында хезмәт коллективларының гына түгел, яшьләр оешмалары, волонтерларның да актив катнашында узачак шимбә өмәләренә район башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы Руслан Морадыймов имзалаган 2015 елның 17 марттагы икеайлык үткәрү турындагы карар башлангыч бирде. Җиңүнең 70 еллыгы елында шимбә өмәләрендә Бөек Ватан сугышы һәм Социалистик Хезмәт Геройлары исемен йөртүче урамнарга аерым игътибар биреләчәк. Шәһәрдә бу чараларны оештыру өчен шәһәр һәм район башкарма комитетлары, коммуналь службалар җаваплы булса, авылларда – авыл җирлекләре башлыклары. Гомумән, предприятие, учреждениеләр җитәкчеләренә, шулай ук иҗтимагый оешмаларга икеайлык барышында даими рәвештә санитар көннәр үткәрү бурычы куела. Бу чорда парклар, зиратларны чистартуга, йорт яны территорияләрендә кече архитектур формаларны, юллар һәм тротуарларны, торак йортлар фасадларын һәм контейнер мәйданчыкларын ремонтлауга, газоннарны тәзекләндерү һәм яшелләндерүгә, торак пунктларда, юл яны полосаларында, халык күпләп ял итә торган урыннарда санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерүгә аерата зур игътибар биреләчәк.

Ә 25 апрельдә "Яшел дулкын" акциясе кысаларында Урман утырту көне игълан ителә. Нурлат урманчылыгы агач утыру һәм урман фондын санитар-экологик чистарту планын эшләячәк. Хәер, урманчылар кайбер эшләрне башлап та җибәргәннәр инде.

- Без автомобиль юллары тирәләрендәге полосаларны чистартуга керештек, кайбер урманчылыкларда яңа беседкалар да урнаштырдык, - ди Нурлат урманчылыгы җитәкчесе Рөстәм Галиев. – Утырту материалын саклау өчен кар көртләре булдырдык, урман техникасын әзерләдек.

*Ахыры 2нче биттә.*

ВАТАНГА ХЕЗМӘТ!

# Егетләрне барлый башлаячаклар

**Бүген, 1 апрельдән старт алачак язгы чакырылыш кампаниясендә быел 99 нурлатлы армия сафларына озатылачак.**

– Бу чорда медицина комиссиясенә 1997-88 елгы 350ләп яшь кешене чакырабыз, - ди район хәрби комиссары Заһир Абдуллин. – Егетләр чакыру кәгазьләре алдылар. Шуларның бер өлеше – наряд буенча 99 егет, язгы чакырылышта армия хезмәтенә озатылачак. Бу чакырылышта төп категория – урта һәм югары уку йортларын тәмамлаган егетләр. Югары белем белән 35 кешене озатырга планлаштырабыз. "С" категориядәге машина йөртүче һөнәренә ия 20 егет тә армиягә әзерләнә. Хәрби хезмәткә озату районда 20 апрельдән башланачак. Егетләребез нигездә коры җир гаскәрләрендә хезмәт итәчәк.

Якын арада армия турындагы законга үзгәрешләр кертү дә планлаштырыла. Повестканы кулга биреп тормыйча, почта аша гына юллау белән бәйле ул. Бу турыда закон проекты әзерләнгән, РФ Дәүләт Думасының оборона комитеты аны хуплаган да инде. Әлеге яңалык үз көченә керсә, хәрби комиссариатларның эше җиңеләячәк: армиягә чакырылучы егетне эзләп йөрисе булмаячак. Почта аша повестка алырга тиешле кеше югалып йөри икән, хәрби комиссариат бу эшне полициягә тапшыра. Хәрби комиссариаттан хәбәр итүләренчә, безнең районда 2013-14 елларда армия хезмәтеннән качып йөрүче 4 кеше бар икән. Бу исемлек полиция бүлегенә юлланган. Аларга карата җинаять эше кузгатылган.

–Яңа закон проекты армиядән качып йөрүчеләргә биш елга чит илгә чыгып китәргә рөхсәт бирмәүне күздә тота, - ди комиссариатның гражданнарны хәрби хезмәткә чакыру һәм әзерләү бүлеге начальнигы Илдус Мазияров. – Моннан тыш, алар дәүләт эшендә, муниципаль хакимият органнарында эшли алмаячак.

Җыелу пунктларында яңа гына хәрби хезмәткә алынучылар өчен армия җыелмасы әзерләнгән. Ул солдат өчен кирәкле шәхси гигиена әйберләре белән комплектланган. Частьларга китәр алдыннан солдатларга биометрик мәгълүматлар белән персональ электрон карталар, банк кредит карталары да биреләчәк.

Узган елның көзендә районнан армия сафларына барлыгы 85 егет озатылган иде. Араларында контракт нигезендә хезмәтне сайлаучылар да бар.

**Зилия ӘКСАНОВА**


Игътибар, яңа бәйге!

## "ДУСЛЫК"КА ЛОГОТИП УЙЛАП ТАБЫГЫЗ

*Хөрмәтле газета укучыларыбыз! Яңа рәсемнәр һәм дизайнерлык эшләре конкурсында катнашыгыз. Моның өчен район газетасының логотибын уйлап табарга һәм ясарга кирәк булачак. Рәсем бер бит зурлыгында һәм газетаның исемен үз эченә алырга тиеш. Фантазиягез ирек бирә икән, район газетасының асылын ачып бирерлек символ уйлап чыгарсагыз да бик яхшы. Рәсемнәрегезне газетаның электрон һәм почта адресына җибәрегез. Эшләр 24 апрельгә кадәр кабул ителә. Бүләкләү – 27 апрельдә.* Җентеклерәк 2-36-20 телефон номеры буенча белешә аласыз.

ВӘЗГЫЯТЬ

# Авыл өчен файдалы арифметика



ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ МӨСЕЛМАН ЗИРАТЫ ШУНДЫЙ БҮГЕН

**Ел башыннан районның 25 авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым җыю турында референдумнар үтте. Аларның барысында да халыкның күпчелеге үзара салым җыюны хуплап тавыш биргән.**

## ИСКЕ ЯҢА "ҮЗАРА САЛЫМ"

"Үзара салым" халык арасында күптән онытылган иске төшенчәләрдән санала. Элегрәк тә авыл халкы турыдан-туры авыл җирлекләре Советлары инициативасы буенча үзләре яшәгән торак пунктларны төзекләндерү, зиратларны, юлларны, күперләрне тәртиптә тоту өчен билгеле бер күләмдә акча җыя иде. 2013нче елның ноябрендә исә ТР Министрлар Кабинетында "үзара салым"-ны 1:4 пропорциясендә өстәмә финанслау турында карар кабул ителде. Димәк, халыктан кергән һәр 1 сум акчага республика бюджетыннан 4 сум өстәмә бирелә. Бу исә муниципаль берәмлекләрне халыкның социаль-икътисадый үсеш һәм яшәү сыйфаты дәрәҗәсен үстерүгә стимуллаштыру йөзеннән башкарыла.

Үзара салым мәҗбүри түгел. Аны кертергәме-юкмы икәнлеген халык референдумда хәл итә. Анда авылда теркәлгән халыкның яртысы катнашып, шуларның яртысыннан артыграгы "әйе" дип җавап бирсә, референдум узган дип санала.

## ИРТӘ ӨЛГЕРГӘН – ОТКАН

Программа 2013нче елда ук кабул ителсә дә, узган елда референдум үткәрергә бары ике – Якушкино һәм Бикүле авыл җирлекләре генә өлгерде. Якушкинода бу средстволарны эштә кулланырга да җитештеләр инде.

- Безнең авыл җирлегендә 5 зират исәпләнә, аларның гомуми территориясе 10 гектардан артыграк һәм торышлары бик яхшы хәлдә түгел иде, - дип үзара салым җыюга этәргән сәбәпләр белән таныштыра Якушкино авыл җирлеге башлыгы Хасибулла Хәмидуллин. – Зиратларны тәртипкә китерү өчен ике еллык программа төзелде. Һәм Советның киңәйтелгән утырышында аны тормышка ашыру максатында гражданнардан үзара салым җыярга дигән карар кабул ителде.

Референдумның беренче тапкыр үткәрелүен истә тотып, агитация эшләре җәелдереп җибәрәләр. Ун йортка бер агитатор билгеләнә, алар һәр гаиләгә кереп, программаның асылын төшендерәләр, халыктан җыелган акчаларның кая юнәлтеләчәген аңлаталар. Шулай итеп, узган елның 1 июнендә Якушкино авыл җирлегендә теркәлгән кешеләрдән 260ар сум күләмендә салым җыю турында референдум үткәрелә.

- Референдумда җирлектә теркәлгән 832 кешенең 712се, ягъни 85,6 проценты катнашты. Аларның 90,9 проценты "әйе" дип тавыш бирде, - ди Хасибулла Хәбибуллович.

Референдумда күмәк катнашкан халык акчаларны да күмәк тапшыра, бер ай эчендә средстволар җыелып, махсус счетка салына һәм авыл җирлеге Советы дәүләт программасында катнашырга дип заявка бирә. Һәм, өстәмә финанслау нәтиҗәсендә авыл җирлеге бюджетында 1 млн.нан артыграк акча барлыкка килә.

- Бу средстволарга барлык биш зиратта да карт агачларны, куакларны, чүпләрне җыештырдык. Ике зират тирәсендә коймаларны алмаштырдык. Православие зиратының 700, мөселман зиратының 430 метрлы коймалары тимер баганалар, профторбалар һәм буялган рәшәткәлекләрдән ясалды, икешәр капка урнаштырылды. Моңа исә үз авылларыбызның вакытлыча эшләре булмаган кешеләрен җәлеп иттек, - ди авыл җирлеге башлыгы.

Шулкадәр күләмле эшләр башкарылуын күреп, авылларның үзара салымга бик каршы булган кайбер кешеләре дә фикерләрен үзгәртә. Һәм инде быел гыйнвар азагында үткәрелгән үзара салым буенча референдумда халык тагы да күбрәк катнаша һәм уңай җавап бирә. Якушкинолылар быел салым акчаларына Якушкино һәм Абрыскино авыллары зиратлары территорияләрен гербицидлар белән эшкәртеп, коймаларын ремонтларга ниятлиләр.

Бикүле авыл җирлегендә исә авыллар халкы референдум үткәреп, үзара салым акчаларын Бикүле зиратын төзекләндерү һәм Илюткинода буаны ремонтлауга тотарга, дип карар иткәннәр. Биредә үзара салым һәм өстәмә финанслау акчаларыннан файдаланырга өлгермәгәннәр әле. Барлык эшләрне апрель аенда, финанс ярдәме килеп ирешкәч башкарырга планлаштыралар. Һәм инде 2015нче ел референдумын үткәрергә әзерләнәләр.

- Быел авыл җирлеге Советы утырышында инициатив төркем референдум үткәреп, үзара салым җыярга һәм средстволарны трактор һәм аңа тагылма җайланмалар алуга тотарга дип тәкъдим итте, - ди Бикүле авыл җирлеге башлыгы Рияз Садыйков. – Үз тракторыбыз авылларның территорияләрен төзек тотарга, юлларны чистартырга ярдәм итәр иде. Халык бу юлы да мәсьәләгә аңлап якын килер һәм хуплап тавыш бирер дип ышанабыз.

## "ҮЗЕБЕЗ ӨЧЕН КИРӘК"

Районда үзара салым буенча референдумнар 25 авыл җирлегендә гыйнвар - март айларында үтте. Авыл җирлекләре үзара салым акчаларын ихтыяҗларыннан чыгып, төрле юнәлешләр буенча тотарга исәпли. Мәсәлән, Андреевка авыл җирлегендә аларны урамнарны яктыртуга, Әхмәттә зиратларны төзекләндерү белән бергә авыл юлларын, җәяүлеләр юлларын һәм буаларны ремонтлауга, Богдашкино, Мамык һәм Төрнәс авыл җирлекләрендә күперләр һәм юлларны төзекләндерүгә юнәлтмәкчеләр. Бер кешедән җыела торган үзара салым суммасы да төрле - 100 сумнан 250 сумга кадәр. Мәсәлән, 22 мартта референдум үткәргән Сәләнгеш авыл җирлегендә аның күләмен 200 сум итеп билгеләгәннәр.

- Сумма авыл халкының хезмәт хакы, керемнәре күләменнән чыгып билгеләнде. Үзара салымнан кергән средстволарны Сәләнгештә юлларны һәм Зүзәйдәге күперне ремонтлауга тотарга ниятлибез, - ди авыл җирлеге башлыгы Анатолий Пинин. - Сүз дә юк, үзара салым күпләр өчен яңа нәрсә, һәм халык арасында да аны куркыбрак каршы алучылар да булмады түгел. Әмма агитация эшләреннән соң халыкның күпчелеге аның асылын аңлады, 95 проценты референдумда катнашып, 68 проценты уңай тавыш бирде.

Сәләнгештән Александр Белов та сайлауда "әйе" дип җавап биргән.

– 200 сум әллә ни зур сумма түгел, безнең гаиләдән 400 сум була инде, аннан гына бөлмәячәкбез, - ди ул. Аның каравы, безнең 200 сумга дәүләттән 800 сум өстәлә, һәм авылны төзекләндерүгә 1000 сум керә булып чыга бит. Шундый мөмкинлектән ничек файдаланмаска ди инде?!

Әлбәттә, халык арасында төрле керемле кешеләр бар, һәм 100–250 сумны да тарта алмаучылар булырга мөмкин. Референдум үткәргәндә бусы да исәпкә алына. Мәсәлән, Якушкино авыл җирлегендә салымнан 18 яшькә кадәргеләр, 1 группа, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш толлары азат ителгән.

### САН

**2015 елда республиканың 745 муниципаль берәмлегендә референдум үткәрү планлаштырыла. Быелның 17 мартына республика бюджетыннан муниципаль берәмлекләргә 277,8 млн. сум күләмендә бюджетара трансферт бүлеп бирелгән.**

## ФАЙДАЛЫ ПРОГРАММА

Үзара салымнар буенча референдумнар район башлыгы Равил Кузюровның да ныклы контролендә. Аның урынбасары Флюра Ногманова үзара салым һәм аның дәүләт тарафыннан өстәмә финанслануы авылларга зур ярдәм дип саный.

- Рәхмәт, авылларда халыкның күпчелеге программаның асылын аңлап тавыш бирде, - ди Флюра Рәшитовна. – Үзара салым акчаларын һәр авыл җирлеге иң тәҗел мәсьәләләрне хәл итү өчен тота ала, программа шунысы белән дә уңайлы. Аннан, авыл җирлекләре үзара салым һәм өстәмә финанслаудан кергән средстволарны бары тик билгеләнеше буенча гына куллана ала, авыл җирлекләре башкарма комитетлары аларны файдалану турында хисап тота. Авыл җирлекләре башлыклары гражданнар җыеннарында да аларның кулланылышы турында халык алдында хисап тотачак. Димәк, халыктан җыелган акча каядыр югалыр, тиешенчә кулланылмас дигән шик булырга да мөмкин түгел.

Хәзерге вакытта районның күпчелек авыл җирлекләрендә халыктан үзара салым акчалары җыю бара. Аларга дәүләттән өстәмә финанс ярдәменең вакытында килүе исә акчаларның тиз арада җыелуына да бәйле. Авыл халкы исә бусын да икенче көнгә калдырмас, дип ышаныч белдерәләр җирле хакимият вәкилләре. Иң беренче чиратта үз авылларыбызның йөзен яхшы якка үзгәртү өчен кирәк бит бу.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

ХӘБӘРЛӘР

## ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕН МАТУР КАРШЫЛЫЙК

Район башкарма комитетының оештыру комитеты нурлатлылар алдына Җиңү көненең юбилей бәйрәмен истәлекле һәм матур итеп үткәрү бурычы куйды һәм үзенең утырышында шәһәрне бизәү мәсьәләсен карады.

Утырышта район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары Әлфия Галәветдинова бу датага аерым мәгънә һәм бәйрәм атмосферасы бирерлек үткәрергә, дип шәһәрне бәйрәмчә бизәү буенча кайбер тәкъдимнәрне җиткерде. "Ветераннар, сугышта катнашучылар яки аларның туганнары яшәгән йортларга тиешле элмә такталар куярга мөмкин булыр иде", – диде ул һәм бу тәкъдимнең тыл хезмәтчәннәренә, производство алдынгыларына да кагылуын билгеләп үтте. Аннан ул җәмәгать транспортын тиешле итеп бизәүләрен сорап автотранспортчыларга мөрәҗәгать итте, ә ЮХИДИгә автомобильләрне Җиңүнең 70 еллыгына иң яхшы бизәүчегә конкурс оештырырга тәкъдим ителде. Утырыштагыларның игътибары парк-скверларның, бигрәк тә һәйкәлләрнең төзеклегенә юнәлтелде. Әлеге корылмалар карарлар нигезендә предприятиеләр, оешмаларга беркетелгән, әмма бу бурычны барысы да тиешенчә үтәп бетерми әле. "Бөек Җиңүнең 70 еллыгын каршылауга әзерлек буенча барлык эшләр дә 1 майга тәгамәлләнергә тиеш», – дип ассызыклады Әлфия Галәветдинова.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

## ИҢ ЯХШЫЛАР АРАСЫНДА

Балык Бистәсендә республиканың социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре арасында "Һөнәре буенча иң яхшы" конкурсының зона этабы үтте.

37 кеше арасында "Гармония" үзәгенең өйдә хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире Елена Селезнева – III, гаиләләргә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтү буенча бүлек белгече Альбина Байбулатова – II һәм Нурлат картлар йортының шәфкать туташы Татьяна Алексашкина IV урыннар алдылар.

**Маргарита ЛИТТА**

# Барыбыз бергә – өмәгә!

*Ахыры. Башы 1нче биттә.*

Шәһәрдә дә төзекләндерү буенча чараларны башкалардан алданрак башлап җибәрүчеләр бар. Мәсәлән, НУАДлылар ике атна элек чокыр ремонтына керешкәннәр, һәм бу вакыт эчендә юлчылар шул максатларга 300 тонна сыек һәм 40 тонна салкын асфальт-бетон катнашмасы файдаланганнар. Территорияне чистартуга беренчеләрдән булып әлеге предприятиенең инженер-техник хезмәткәрләре дә чыкты: дүшәмбене алар санитар сәгать белән башлап җибәрделәр. Автомобиль юллары идарәсе хезмәткәрләре үзләренә беркетелгән территория – юл кичүе һәм әйләнеч юлда да шимбә өмәләрен җиренә җиткереп үткәрергә планлаштыралар. Кыскасы, шәһәрнең бер генә почмагы да кагылмаган көенчә калырга тиеш түгел: барлык юллар һәм урамнар да төзекләндерү һәм яшелләндерү өчен предприятие һәм оешмаларга беркетелгән, ә икеайлык кысаларындагы барлык эшләрне районның экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча комиссиясе координацияләячәк. Нурлатлыларга исә икеайлыкка актив кушылырга гына кала. Ә эшне гади нәрсәләрдән, мәсәлән, йортларның отмосткаларын кардан арындырудан башларга була...

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

# ВАКЫТ. ВАКЫЙГА. РЕКЛАМА

ВАТАНГА ХЕЗМӘТ

## “Аҗаган” тәҗрибәсе армиядә булыша

**Быелгы “Аҗаган” республика хәрби-спорт уеннарының зона турында Нурлат данын гимназия укучылары яклаячак.**

Узган атнада “Аҗаган”ның муниципаль туры үтте. Анда үз кустларында җиңү яулаган шәһәрнең 1, 2, 3, 4 һәм 9нчы мәктәпләре, гимназия һәм Яңа Иглай укучылары көч сынашты. Быел егет-кызларга җиде төрле сынауда үз әзерлекләрен күрсәтергә туры килде. “Автомат сүтеп җыю, мылтыктан ату, йөгерү, граната ташлау кебек традицион бәйгеләрдән тыш тарихка багышланган интеллектуаль уен да, “Россия символлары” исемле плакатлар ярышы, гомумгаскәри саклану комплектын киеп-салу кебек үзенчәлекле төрләр дә бар”, – ди ярышларны оештыручы “Форпост” яшьләр формированиесенең Нурлаттагы директоры Альберт Садретдинов. Шул рәвешле, үсмерләр гимназиядә, шәһәр стадионында, паркта, тирда көне буе үз осталыкларын күрсәттеләр. Оештыручылар әйтүенчә, булачак Ватан сакчыларының быелгы “Аҗаган”га ныклап әзерләнүләрен күрергә була иде. Хәер, мондый ярышларда катнашучыларның күпчелеге, гадәттә, спортны да кече яшьтән үк дус итә, укуда да алдынгылар сафында була. Мисал өчен, Яңа Иглайдан Нәфис Шәрипов турникта егерме тапкыр тартылып күпләрне сокландырды. Баксаң, егетнең бу җәһәттән үз шөгыльләнү системасы бар икән. “Спорт белән шөгыльлән, һәрчак кирәге чыга, армиягә барсаң бигрәк тә, дигән иде әтием. Турникта исә үзеңә ничә яшь – шул кадәр тартыл, дип тә өстәде. Ул чагында миңа унике яшь иде, турникта дүрт тапкыр гына тартыла алгач, гарьләндем, шуннан ныклап шөгыльләнә башладым. Шөкер, бүген күрсәткечләрем йөз кызартырлык түгел”, – ди Нәфис. Гомумән, һәр елны үзләренә нинди-дер стимул уйлап табу, һәм, куйган максатларына ирешү “Аҗаган”да катнашучы үсмерләрнең күбесенә хас. Әнә, ОБЖ һәм физкультура укытучысы Дилүс Җәлалетдинов җитәкчелегендәге гимназия командасындагы егет-кызларның һәркайсы гүя иртәгедән үк Ватан сагына китү бурычын тоеп эш итте, бар күңелләре белән ярыш рухына бирелгәннәр иде алар. Шуңа гомуми нәтиҗәләр буенча да I урынны яулый алдылар. Хәзер исә Чистайдагы зона этабында Нурлат данын якларга әзерләнәләр гимназистлар.

Илназ МӨБАРӘКШИН




ГОМУМГАСКӘРИ САКЛАНУ КОМПЛЕКТЫН КИЕП-САЛУ АВЫР БУЛСА ДА, КЫЗЫКЛЫ ЯРЫШ ИДЕ

ПРОКУРАТУРА ТИКШЕРҮЛӘРЕ

### ЭШМӘКӘР ЗАКОННЫ ҮТӘМӘГӘН

**Нурлат шәһәр прокуратурасы Нурлат эшмәкәренең җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә һәм террорчылыкны финанслауга каршы тору турындагы законның үтәвен тикшергән.**

Ул түләүләрне кабул итүче оператор буларак, эчке контрольне оештыруда законның үтәлешен тәэмин итмәгән, ягъни алда күрсәтелгән законның үтәлеше йөзеннән кассир-операционист өчен беренчел, өстәмә һәм максатчан инструктаж үткәрмәгән. Шулай ук шәхси предприятиедә җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерү һәм террорчылыкны финанслауга каршы тору максатыннан булдырылган эчке контроль кагыйдәләрендә инде үз көчен югалткан норматив актларга сылтамалар да бар. Прокуратура эшмәкәргә карата представление чыгарды.

### КЫШ ӨЧЕН ЯЗЫН ҖАВАП БИРӘСЕ

**Нурлат прокуратурасы Нурлат шәһәрендә юл хәрәкәте иминлеге турындагы федераль закон таләпләренең үтәлешен тикшерде.**

Нурлат шәһәрендәге кайбер урамнарның юл өслеге ГОСТ таләпләренә җавап бирми. Кар көртләре җәяүлеләр юлыннан 5 метр, җәмәгать транспорты тукталышыннан 20 метрдан да якынрак өелергә тиеш түгел. Гыйматдинов урамының 60нчы һәм Совет урамының 137нче йортлары янындагы җәяүлеләр юлларында 1 метрдан биегрәк кар көртләре булуы ачыкланды.

### ҖИР КАГЫЙДӘСЕ ҮТӘЛӘМЕ?

**Нурлат шәһәр прокуратурасы җир законының үтәлешен тикшерде.**

Тикшерү барышында бер нефть компаниясенең җир законын бозып, җир участогын максатчан кулланмавы ачыкланды. Прокуратура генераль директорга карата административ хокук бозу турында эш кузгату хакында карар чыгарды.

### ИНТЕРНЕТТА ДА ЗАКОН БОЗАЛАР

**Нурлат шәһәр прокуратурасы Интернетта закон бозу очрагын ачыклады.**

Тикшерү “Вконтакте” социаль челтәреннән файдаланучы берәүнең үз битендә гашиш маен әзерләү һәм тарату турында язу урнаштыруын ачыклады, бу исә федераль законны бозу булып исәпләнә.

Нурлат шәһәр прокуратурасы “Вконтакте” социаль челтәреннән файдаланучының битендә урнаштырылган мәгълүматны тарату тыелган итеп тану турындагы искны судка юллады.

Яков ВЛАСОВ, Нурлат шәһәр прокуратурасы.

МӘШГУЛЬЛЕК

### ТЕЛӘК КЕНӘ БУЛСЫН

**Нурлат шәһәре халкының мәшгульлеге үзәгендә быел 118 өлкән яшьтәге кешене компьютер серләренә өйрәтергә планлаштыралар. Шул максаттан ел дәвамында биш төркем өчен 72шәр сәгатьлек укулар оештырылачак.**

– Өлкәннәр дәресләрдә компьютерның гомуми төзелешен өйрәнәләр, офис программалары белән танышалар, Интернетта, социаль челтәрләрдә эшләргә өйрәнәләр. Укулар өлкәннәрне электрон хөкүмәт порталы хезмәтеннән файдаланып, торак-коммуналь түләүләрне өйдән чыкмыйча компьютер аша башкарырга өйрәтүне дә күздә тота, - ди үзәкнең әйдәп баручы инспекторы Фәния Хәсәнова. – Пенсионерлар һәм пенсия алды яшендәгеләр өчен укулар бушлай оештырыла. Укулар тәмамлангач, һәркем компьютер курслары үтүе турында сертификат алачак. Дәресләрне төркемнәр тупланып бетү белән башлап җибәрәчәкбез.

Курсларга язылу өчен бернинди документлар җыярга да кирәкми, бары тик пенсия таныклыгын алып, мәшгульлек үзәгенә генә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

### Апрельгә намаз вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Зәвәл вакыты | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.04.2015 | 3:40 | 5:10 | 11:40 | 12:00 | 16:05 | 18:12 | 19:56 |
| 02.04.2015 | 3:37 | 5:07 | 11:40 | 12:00 | 16:06 | 18:14 | 19:59 |
| 03.04.2015 | 3:35 | 5:05 | 11:40 | 12:00 | 16:08 | 18:16 | 20:01 |
| 04.04.2015 | 3:32 | 5:02 | 11:39 | 12:00 | 16:09 | 18:18 | 20:03 |
| 05.04.2015 | 3:30 | 5:00 | 11:39 | 12:00 | 16:11 | 18:19 | 20:06 |
| 06.04.2015 | 3:28 | 4:58 | 11:39 | 12:00 | 16:12 | 18:21 | 20:08 |
| 07.04.2015 | 3:25 | 4:55 | 11:39 | 12:00 | 16:13 | 18:23 | 20:11 |
| 08.04.2015 | 3:23 | 4:53 | 11:38 | 12:00 | 16:15 | 18:25 | 20:13 |
| 09.04.2015 | 3:20 | 4:50 | 11:38 | 12:00 | 16:16 | 18:27 | 20:16 |
| 10.04.2015 | 3:18 | 4:48 | 11:38 | 12:00 | 16:17 | 18:29 | 20:19 |
| 11.04.2015 | 3:15 | 4:45 | 11:37 | 12:00 | 16:19 | 18:31 | 20:21 |
| 12.04.2015 | 3:13 | 4:43 | 11:37 | 12:00 | 16:20 | 18:33 | 20:24 |
| 13.04.2015 | 3:10 | 4:40 | 11:37 | 12:00 | 16:21 | 18:35 | 20:27 |
| 14.04.2015 | 3:08 | 4:38 | 11:37 | 12:00 | 16:23 | 18:37 | 20:29 |
| 15.04.2015 | 3:06 | 4:36 | 11:36 | 12:00 | 16:24 | 18:38 | 20:32 |
| 16.04.2015 | 3:03 | 4:33 | 11:36 | 12:00 | 16:25 | 18:40 | 20:35 |
| 17.04.2015 | 3:01 | 4:31 | 11:36 | 12:00 | 16:26 | 18:42 | 20:38 |
| 18.04.2015 | 2:59 | 4:29 | 11:36 | 12:00 | 16:28 | 18:44 | 20:41 |
| 19.04.2015 | 2:56 | 4:26 | 11:36 | 12:00 | 16:29 | 18:46 | 20:43 |
| 20.04.2015 | 2:54 | 4:24 | 11:35 | 12:00 | 16:30 | 18:48 | 20:46 |
| 21.04.2015 | 2:52 | 4:22 | 11:35 | 12:00 | 16:31 | 18:50 | 20:49 |
| 22.04.2015 | 2:49 | 4:19 | 11:35 | 12:00 | 16:33 | 18:52 | 20:52 |
| 23.04.2015 | 2:47 | 4:17 | 11:35 | 12:00 | 16:34 | 18:54 | 20:55 |
| 24.04.2015 | 2:45 | 4:15 | 11:35 | 12:00 | 16:35 | 18:56 | 20:59 |
| 25.04.2015 | 2:42 | 4:12 | 11:34 | 12:00 | 16:36 | 18:57 | 21:02 |
| 26.04.2015 | 2:40 | 4:10 | 11:34 | 12:00 | 16:38 | 18:59 | 21:05 |
| 27.04.2015 | 2:38 | 4:08 | 11:34 | 12:00 | 16:39 | 19:01 | 21:08 |
| 28.04.2015 | 2:36 | 4:06 | 11:34 | 12:00 | 16:40 | 19:03 | 21:11 |
| 29.04.2015 | 2:34 | 4:04 | 11:34 | 12:00 | 16:41 | 19:05 | 21:15 |
| 30.04.2015 | 2:32 | 4:02 | 11:34 | 12:00 | 16:42 | 19:07 | 21:18 |

**Закупаем**

**платы, 50 руб./кг.**

**Т. 8-903-307-53-97.**

НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ.
Низкие цены.
8-927-242-48-68.

Решение от 15.03.2015 г. о результатах местного референдума 15 марта 2015 года на территории Тимерлекского сельского поселения Нурлатского муниципального района по вопросу введения и использования средств самообложения граждан размещено на официальном сайте Нурлатского муниципального района в разделе «Тимерлекское сельское поселение».

Открылась аптека
**«Казанские аптеки»**
**Адр.: г.Нурлат, ул. Гиматдинова, д.81.**

**Салон «ДОКТОР ОПТИКА»**
* Изготовление очков любой сложности.
Быстро и качественно.
* Подбор мягких контактных линз.
* Цветные контактные линзы.
* Солнцезащитные очки, аксессуары.
**г. Нурлат, ул. Советская, 120,**
**т.: 2-17-88, 8-927-427-79-27,**
**ул. Гиматдинова, 81,**
**т.: 2-91-99, 8-937-610-69-30,**
**ТЦ «Нурлатский», секция №10**
**Т. 8-937-613-99-88,**
**ТЦ «Шифа», ул. Кариева, 1Д**
**Т. 8-927-246-56-55.**
Лиц. №16-01-000675 от 13.12.2007г., выд. Фед.службой по надзору в сфере здравоохранения и соц.развития.
Имеются противопоказания.
Необходима консультация специалиста.

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Киекле авылында** гомер кичерүче газиз әниебез **Сәрия Закир кызы Мөхәммәтованың** 1 апрельдә гомер бәйрәме – юбилее.

Әниебез! Сиңа гомернең озынын, саулыкның ныгын, тормышның иң матурын телибез.

Авырлыклар килсә тормышта,
Киңәш сорап сиңа киләбез,
Дөрес юлга бастырырдай сүзләр
Әйтәсеңне алдан беләбез.
Маңгаеңа төшкән аксыл чәчләр
Сөйкемлелек бирә йөзеңә,
Барысы өчен рәхмәт сиңа, әнкәй,
Исәнлегең белән йөз яшә!

**Иң изге теләкләр белән барлык балаларың исеменнән кызың Розалия.**

**Иске Әмзәдә** яшәүче **Ирек Нәбиуллинны** туган көне белән ихлас күңелдән котлыйм. Аңа бәхетле тыныч гомер, тормыш иптәше Люция белән тигез һәм матур тормыш телим. Тырышлыгыгыз һәм уңганлыгыгыз белән булдырган түгәрәк тормышыгыз кителмәсен, балаларыгызның рәхәтен күреп яшәгез.

Йөрәгеңә җыйган
яхшылыклар
Изгелекләр булып
кайтсыннар.
Туар таңнар алып
килсен сиңа
Сәламәтлек, бары
шатлыклар!

**Яңа Әмзәдән Сания Фәтхетдинова**

## КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК

*Йорт, Биляр Озерода. Т. 8-927-475-95-29.

*2 бүлмәле фатир, үзәк, 44 кв.м. Т. 8-937-287-60-84.

*Төзелеп бетмәгән йорт, Көньяк-көнбатыш мкр., Сембер ур.,17. Т. 8-927-466-21-44.

*Йорт, т/ю. Яки алмаштырыла. Т. 8-937-580-20-18.

*Рус. Богдашкиносында йорт. Т. 8-960-841-14-68.

*Йорт ( Интернационалистлар ур., 22-2). Яки Яр Чаллыга алмаштырыла. Т.: 8-927-037-45-67, 8-927-426-97-57.

*Йорт, үзең алып китәргә. Т. 8-987-404-29-94.

*1 бүлмәле фатир, ул. Мәктәп ур., 26, 830000 сум., сатулашу; 2 бүлмәле фатирлар: Нурлат ур.,18, Гыйматдинов ур., 56, йорт, Тукай ур., 180 кв.м. Т. 8-937-600-47-73, Алсу.

*2 бүлмәле фатир, Салимҗанов ур., 13, индивидуаль җылытылу белән, ремонт, ишегалдында гараж . Т. 8-917-884-63-05, Әнвәр.

*1-комнатная квартира. Т. 8-937-580-57-63.

*1-комнатная квартира по ул. Гиматдинова (аэропорт), 1 этаж, 26 кв.м. Т. 8-927-484-45-51.

*две 3-комнатные квартиры (мкр. Яшлек, с/з). Т. 8-937-283-18-83.

*земельный участок, ж/д. Т. 8-927-479-74-02. П/с 16-16-03/00912008-246.

*дом, ул. Михеева. Т. 8-937-77-40-132.

*дом. Варианты. Т. 8-937-283-86-00.

*2-комнатная квартира, ул. Самаренкина. Т. 8-937-617-09-71.

*2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 9, 1400 тыс.руб. Т. 8-937-003-36-39.

*3-комнатная квартира, ул. Самаренкина, 6, 3 этаж, площадь 62,8. Т. 8-927-481-71-39.

*1-комнатная квартира. Т. 8-937-525-04-46.

## АВТОТРАНСПОРТ

***АШЫГЫЧ, ВАЗ-2107, 2005 ЕЛГЫ. Т. 8-937-28-11-830.**

*«Лада Калина». Т. 8-929-723-02-06

*«ВАЗ-2114»,2012 елгы, яхшы хәлдә. Т. 8-937-297-07-99.

*«Шевроле Авео», 2010 елгы. Т. 8-927-455-44-98.

*«ДТ-75», бульдозер, 4 төрәнле сабан, арба, тентлы «УАЗ-469». Т. 3-72-90.

*«ВАЗ-2110», яхшы хәлдә. Т. 8-927-671-93-17.

*«ГАЗ-53», самосвал. Т. 8-937-775-21-68.

*«Лада Гранта», 2012 г/в, пробег 18000 км. Т. 8-937-285-53-54.

*«ВАЗ-2199», 2003 г/в. Т. 8-937-520-94-25.

*«УАЗ-315122», 2002 г/в., 50 000 руб. Т. 8-927-476-58-20.

## БАШКАЛАР

*Яшь тавыклар. Т. 8-927-483-06-10, 8-917-293-27-47.

*Казлар, каз эч-башлары. Т. 8-929-726-57-63.

*Елга комы, ОПГС, керамблоклар, бордюрлар, туфраклы вак таш, читләре алынмаган усак, нарат буралар. Т. 8-937-594-31-79, Айдар.

*Утын, ПГС. Т. 8-937-617-11-21.

*«Муравей» мотороллеры, «Урал» мотоциклы, бишекле. Т. 8-927-679-58-67.

*Ярган материаллар, утын. Т. 8-927-044-80-91.

*R-16 коелган дисклары, комплектта, кыйммәт түгел. Т. 8-937-283-03-72.

*Умарта гаиләләре. Т.: 8-937-528-78-69, 8-927-677-87-41.

*ПГС, вак таш, ком. Т. 8-917-930-75-37.

*Үгез бозау, 1 айлык. Т. 8-937-525-03-51.

*Балкон рамнары, арзан. Т. 8-927-415-47-81, 8-927-481-78-69.

*Ярган утын («КамАЗ»). Т. 8-937-775-21-68.

*Сыерчык оялары. Т. 8-937-570-50-55.

*Стенка-горка. Т. 8-987-404-29-94.

*жеребая кобыла. Т. 8-927-400-81-04.

*резина «Кама евро-129», 175/65 R-14. Т. 8-927-040-64-27.

*коровы (45000 руб.), бочка для реализации молока (100 тыс.руб.). Т. 8-927-600-27-05.

*пчелосемьи. Т. 8-906-333-08-58.

*пшеница. Доставка. Т. 8-937-776-33-35.

*бык на мясо. Т. 8-927-435-31-49.

*оптом огурцы свежие, тепличные, местные из Нурлатского района. Т. 8-927-679-54-19.

*ПГС, песок, буткамень. Т. 8-927-247-27-37.

*паласы, дешево. Т. 8-917-895-33-76.

*кухонный гарнитур, б/у 2 года. Т. 8-937-003-90-59.

*пчелосемьи «карпатка», мед, рамкомплекты собранные, навощенные, инвалидная коляска, электрическая плита. Т. 8-937-292-86-45.

*пчелы. Т.: 2-17-06, 8-927-246-98-83.

*организация распродает двигатель «КамАЗ», «ГАЗ»; а/м «ЗИЛ» («бычок»), 2007 г/в. Т. 8-927-207-61-92.

*инвалидная коляска. Т. 8-927-677-51-78. *песок, ПГС, бут.камень, битый кирпич. Т. 8-9274-777-333.

*кирпич новый (Кар.Гора). Т. 8-929-728-93-36.

*ПГС, песок, буткамень. Т. 8-927-247-47-17.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

***Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.**

***Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.**

*Электрик хезмәтләре. Т. 8-987-418-35-00.

***Жалюзиның барлык төрләре, тиз. Т. 8-927-672-01-17.**

*Видеога, фотога төшерү. Т. 8-937-298-37-27 (Сергей).

*Тамада. Т. 8-927-416-18-07.

*Теләсә нинди катлаулылыктагы җылыткыч, канализация, суүткәргеч. Т. 8-937-772-43-81.

*Суыткычлар төзәтү. Т. 2-71-69, 8-937-610-58-78.

*Сантехника (су, канализация, җылыту). Т. 8-937-526-56-86.

*Өйгә килеп суыткычлар төзәтү. Т. 8-917-246-73-10.

* Компьютерга ярдәм. Т. 8-909-308-22-56.

*Электр монтажлау эшләре. Т. 8-929-728-93-36.(Наличный и безналичный расчет)

*Йөк күчерү, «ГАЗель», тент, 4,20. Т. 8-927-442-38-10.

*Компьютерлар төзәтү. Т. 8-927-474-71-20.

***Фатирлар ремонтлау (плитка, ванналар, сантехника). Т. 8-927-446-99-98.**

*чистим колодцы. Т. 8-939-393-37-24.

*копаем фундаменты, чистим колодцы. Т. 8-939-393-37-24.

*г/п «КамАЗ», 5 т., тент, длина 6 м. Т. 8-987-207-85-89.

*услуги каменщика. Т. 8-927-246-04-39.

## БИРЕП ТОРЫЛА

*Командировкадагыларга тәүлекләп һәм сәгатьләп фатир. Т. 8-927-456-05-69.

*2 бүлмәле фатир. Т. 8-937-599-74-40.

*1-комнатная квартира, ул. Нурлатская. Т. 8-987-414-02-42

*2-комнатная квартира на длительный срок. Т. 8-927-447-62-99.

*2-комнатная квартира, мкр. Яшлек. Т. 8-927-044-00-19.

*1-комнатная квартира, ж/д. Т. 2-93-44.

## ЮГАЛТУЛАР

*утерянный аттестат АО 855616 об основном общем образовании, выданный Андреевской восьмилетней школой в 1981 году на имя Владимира Викторовича Гаврилова, считать недействительным.

*утерянный аттестат 16 АБ 0045570 о среднем (полном) общем образовании, выданный МБОУ Ново-Иглайкинской средней общеобразовательной школой Нурлатского района Республики Татарстан 18 июня 2011 года на имя Регины Радиковны Юнусовой, считать недействительным.

*пропали собаки (охотничьи, русские гончие, выжлецы). Вознаграждение. Т. 8-937-584-40-06.

## КИРӘК

*Чәчтараш, 60%. Т. 8-937-287-68-88.

*Яшьлек мкр.нан 2 бүлмәле фатир, кайнар су белән. Т. 8-937-520-94-24.

*охранник. Т.: (884345) 2-78-66, 8-937-770-11-72, с 8.00 до 17.00.

*секретарь-делопроизводитель с высшим образованием, опыт работы от 1 года, грамотная устная и письменная речь, уверенный пользователь ПК, знание офисных программ. Резюме направлять на эл.почту nkazachkova@agro-razvitie.ru, т/факс 4-02-50.

*ООО «ТНГ-Контур» бурильщики, машинисты подъемного агрегата для работы в районе Аксубаева. Т.: 8-917-851-36-32, 8(85557)3-97-30, 3-73-39.

*ОАО «Агро-Развитие Плюс» секретарь-делопроизводитель, водители на автомашины «КамАЗ» и бензовоз, снабженец. Т. 4-02-50.

*продавец м-н «Автозапчасти». Т. 8-927-413-55-30.

*массажист с мед.образованием. Т.: 2-43-03, 2-43-04.

## САТЫП АЛАМ

***Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.**

*КЫЙММӘТКӘ АВТО. Т. 8-937-588-36-46.

*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.

*Мөгезле эре терлек. Т. 8-927-481-30-38.

*куплю раму «ГАЗ-69». Т. 8-927-245-28-22.


*бетономешалку на 220V. Т. 8-937-297-83-77.


**Магазин «Ковры»**
*Постоянные скидки 10%*
на КОВРЫ, ПАЛАСЫ, ДОРОЖКИ
**Г. Нурлат, ул. Гиматдинова, 79. Т. 2-09-89.**
ООО «ЛИДЭР»

**«KRAUSS» ПЛАСТИК ТӘРӘЗӘЛӘРЕ**
**2015 елның 1 гыйнвареннан 31 декабренәчә**
**5 тәрәзәгә заказ биргәндә, 6нчысы бүләккә***
**Авыл тәрәзәләре 2000 сум.**
**Откослар, тәрәзә төпләре, москит челтәрләре.**
**Бөтен Татарстан буенча эшлибез.**
**%сыз бүлеп түләү (банклар катнашыннан башка).**
***җентеклерәк 8-9274-000-606, 8-9272-449-000 тел. буенча.**
**«Свет-Окон» ОООсы.**

**4 апреля в поликлинике ЦРБ ведут прием специалисты МДЦ г.Казань по следующим направлениям:**
эндокринология
неврология
кардиология
сосудистая хирургия (с аппаратурой).
**Врачи проведут исследования на высокотехнологичном оборудовании.**
**Т. 8-917-269-54-27.**
Имеются противопоказания.
Необходима консультация специалиста.

**Умартачылар игътибарына!**
Ветеринария даруханәсе кәрәз сата һәм балавыз кабул итә. Шулай ук сатуда препаратлар һәм инвентарь.
*Гыйматдинов ур.,52.*
***Т. 8-927-406-14-77.***

***ВНИМАНИЕ!!!***
**Скидки на все окна 30%**
*Компания " Оконные системы"*


**Окно 1300х1400**
**Поворотно-откидная створка**
**Подоконник 300 мм**
**Отлив 150мм**
**Монтаж с демонтажем**
**При заказе более 2-х окон - ПОДАРОК***

| Rehau | KBE | Salamander | Novotex |
|---|---|---|---|
| 7700руб | 7200руб | 6500руб | 6000руб |

**т.8-927-742-66-67, 8-917-953-95-12**
*Акция действует с 01.04.15 по 30.04.15 г. Подробности по указанным телефонам. Организатор: ООО «СВК». Реклама.

**Только 3 апреля**
*в здании типографии,*
*ул. К.Маркса, 19, 2 этаж*
состоится ярмарка-распродажа **МЕХОВЫХ ИЗДЕЛИЙ.** Шубы из мутона, норки, бобра (г. Пятигорск). Дубленки и мужские кожаные куртки.
**Акция: Сдай старую шубу за 5000 рублей (акция действует при осуществлении покупки). Скидки до 50%.* Кредит. Рассрочка.****
*Подробности у продавцов.
Организатор акции ИП Панченко М.Г.
**Кредит, рассрочку предоставляет АО «ОТП Банк».
Реклама


## АЛМАШТЫРЫЛА

*Йортны - фатирга. Т. 8-927-461-98-97.

## ТАНЫШЫРГА ТЕЛИМ

*женщина 71 год, русская, без в/п познакомится с мужчиной без в/п для совместного проживания. Т.: 2-27-16, 8-937-587-17-80.


**Обивка мягкой мебели. Доставка. Т.: 8-927-676-51-45, 2-80-31.**

**Европа сыйфатына ия ТАРТТЫРЫЛМА ТҮШӘМНӘР**
**2015 елның 24 мартыннан 30 апреленә кадәр 4 түшәмгә заказ биргәндә, 5нчесе - бүләккә!**
*3 айга бүлеп түләү (банклар катнашыннан башка).*
**Җентеклерәк 8-937-776-32-46 т. буенча.**
*ИП Зигангиров А.А.*

**В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ ИЗ Г. КАЗАНИ ПО СЛЕДУЮЩИМ НАПРАВЛЕНИЯМ:**

4 апреля 2015 года
1. Кардиология, ревматология.
2. Взрослая, подростковая гинекология, лечение бесплодия.
3. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследование сердца, эхокардиоскопию с ЦДК.

5 апреля 2015 года
1. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии. Ведение беременности.
2. Диетология.
3. Аллергология, иммунология. Решение проблем бронхиальной астмы, аллергических дерматитов, кожных заболеваний.
4. Андрология. Помощь при эректильной дисфункции, ЗППП, мужском бесплодии, хр.простатите, аденоме предстательной железы.

11 апреля 2015 года
1. Кардиология, ревматология.
2. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии. Ведение беременности.
3. Диетология.
4. Неврология.
5. Урология, андрология. Помощь при эректильной дисфункции, ЗППП, мужском бесплодии, хр.простатите, аденоме предстательной железы.
6. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследования сосудов головного мозга, верхних и нижних конечностей, органов малого таза, плода на 1, 2 и 3 триместрах.
7. Сосудистая хирургия.

Реклама

**КДЦ предлагает решение проблем мелких вен, сосудистых паутин на ноге. Предлагает услуги по ДМС через Нурлатский филиал СК «Чулпан». Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.**

ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г. ОГРН 1021605358103.

**Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста**



**Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" АҖ** www.tatmedia.ru www.nurlat-tat.ru **Реклама хезмәте телефоны:** 8 (84345) 2-36-12

"Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасы
Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

"Татмедиа" АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир С.Н. Хәйруллина
Тел.: 2-36-14

**Редакциянең адресы:**
423040, ТР, Нурлат шәһәре, К.Маркс ур., 19
**Электрон адрес:** e-mail: redak@list.ru
**Телефоннар**: 2-36-12 – җаваплы сәркатип, реклама бүлеге, факс
2-36-20 – рус бүлеге
2-36-13 - корреспондентлар
2-25-88 – бухгалтерия

**Нәшер итүче:**
"ТАТМЕДИА" АҖ 420097, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы (Татарстан) идарәсе тарафыннан 2013 елның 16 маенда теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы: ПИ № ТУ 16-01018
Бу сан "Татмедиа" АҖ филиалы
"Идел – Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды
Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2.
Басуга тапшыру вакыты:
график буенча – 14.30,
фактта – 14.30

татмедиа

Тираж - 1855

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булып чыгарга мөмкинлеге юк.
**Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
Реклама белдерүләренең төгәллеге өчен реклама бирүче үзе җаваплы.

Газета **чәршәмбе** һәм **җомга** чыга.
Заказ №5932
Язылу индексы – 16185
Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

12+


© Язмаларны күчереп бастыру редакциянең язмача рөхсәте белән генә мөмкин.